КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 ноябрь г.Казань № 979

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Модульле теплицалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Эшен башлап җибәрүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен.».

әлеге карар белән расланган Нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

9 нчы пунктның тугызынчы абзацында «(сөт һәм ит юнәлешләрендәге мөгезле эре терлекләрдән тыш)» сүзләрен «(дуңгызлар, сарыклар, атлар, беренче буын гибдир дуңгызлар)» сүзләренә алыштырырга;

33 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап финанс елының 1 октябреннән 31 декабренә кадәрге чорда мөгезле эре терлектән бозаулар үрчемен алу;»;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктның беренче абзацында «кимендә бер календарь ел гамәлгә ашыручы» сүзләреннән соң «һәм (яки) хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында чәчүлек мәйданнарын арттыручы» сүзләрен өстәргә;

Тәртипнең 5 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында чәчүлек мәйданнары арттырылган очракта, субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$W_у = (П – П_{ог}) х 60,0 х 5,0,$$

монда:

$W_у$ – хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында чәчүлек мәйданнарын арттыруны стимуллаштыруга субсидия күләме, сум;

П – агымдагы финанс елында субсидия алучыда булган авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары, гектар;

$П_{ог}$ – хисап финанс елында субсидия алучыда булган авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары, гектар;

60,0 – 1 гектар чәчүлек мәйданына субсидиянең минималь ставкасы, сум;

5,0 – хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында чәчүлек мәйданнарын арттырган субсидия алучыга карата субсидияне исәпләп чыгарганда кулланыла торган төзәтү коэффициенты»;

6 нчы пунктта «10,0» саннарын «30,0» саннарына алыштырырга, «рәсми статистика» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хисап финанс елында алучыда булган авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары турындагы мәгълүмат (гектарларда) – субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары арттырылган очракта.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән олырак булган кәҗәләрне карап тотуга чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 5 нче пунктындагы бишенче абзацта «1000» саннарын «500» саннарына алыштырырга;

әлеге карарга Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Модульле теплицалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Эшен башлап җибәрүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин